Татарстан яшьләре

№ 6

(8806)

СИШӘМБЕ

13 июль, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.


• ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ • 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА •

Акрын кирәк, иплән кирәк

Украина белән Русия Кара диңгез флотын бүлешкәндә Татарстан Президенты флот командующие белән уртак тел таба

М.Шәймиев үткән атнада Кырымда булды. Кайбер усал телләләр Президентның анда ике яклы килешүдә Татарстан хөкүмәте өчен каралган ял итү урыннарын күреп йөрүен әйтсә дә, рәсми хәбәрләрдән күренгәнчә, Татарстан Президенты дәүләт мәнфәгатьләрен кайгырту белән мәшгуль. Аерым алганда ул Кырым Республикасы ЮС Рәисе белән ике яклы икътисадый килешүне тормышка ашыру юллары турында сөйләшкән һәм Берләштерелгән Кара диңгез флоты командующие белән очрашкан. Украина белән Русия өчен генә түгел, Татарстан өчен дә бик әһәмиятле икән Кара диңгез. Якын киләчәктә үзенең нефть ташу флотын булдыруны максат итеп куйган Татарстан өчен Кара диңгез дөньяга чыгуның иң төп юлы. Нәкъ менә шуның өчен М.Шәймиев флот командующие Э.Балтин белән ике якның да мәнфәгатьләрен күздә тоткан мәсьәләләрне тикшергән. Командующийның Президентны "Безукоризненный" сакчы корабле белән таныштыруы сөйләшүләр нәтиҗәсез калмаган дип фараз итәргә мөмкинлек бирә.

Сөйләшүләрдә Премьер-министр урынбасары Р.Моратов, "Татнефть" берләшмәсе генераль директоры Р.Галиев һәм башка рәсми затлар катнашкан.



Йолкымагыз!

Бигрәк тә үзегез сокланган чәчәкне.

Җимерек урыннары артык күп булса да, башкалабызда рәхәтләнеп ял итәрлек, тирә-яктагы матурлыкка хозурланып йөрердәй җирләр җитәрлек. Евгений Канаевның бу рәсемендә сез шундый урыннарның берсен - Г.Камал театры янындагы мәйданны күрәсез. Ә бу чәчәк тулы савытларны бирегә шәһәрне яшелләндерү хуҗалыгы урнаштырган. Бәлки Казанда мондый урыннар күбрәк тә булыр иде, ләкин үзебезнең мәнсезлегебез моны булдырмый кала бугай. Шул ук шәһәрне яшелләндерү хуҗалыгы хезмәткәрләре әйтүенчә, театр янындагы чәчәкләрне бер тәүлек эчендә йолкып бетерә язган булганнар.

Е. КАНАЕВ фотосы.



Барысы да безнең белән килешә

Вице-президент В.Лихачев Түбән Новгородта булды. Ул анда өлкәнең губернаторы Б.Немцов һәм Ислам мәдәни үзәге вәкилләре белән очрашты, шәһәрнең Җәмигъ мәчетен карады. Визит барышында Татарстан белән Түбән Новгород өлкәсе арасындагы килешү әзерләнде һәм аңа кул куелды. Татарстан җитәкчеләренең тел төбен аңларга теләүчеләр өчен В.Лихачев матбугат конференциясе үткәрде.

Хәрбиләр белән хөкүмәт телендә аңлашу

Премьер-министр М.Сабиров Казан шәһәрендә һәм шәһәр тирәсе районнарында урнашкан хәрби частьларда булды. Ул солдатларның казармаларын карап йөрде, аларның көнкүреше белән кызыксынды. Хөкүмәт җитәкчесенең хәрбиләр турындагы кайгыртуы солдат һәм офицерлар күңелендә рәхмәт хисләре уятты. Запаска китүче хәрби хезмәткәрләр алга таба хокук саклау органнарында эшләргә теләүләрен белдерделәр. Премьер-министр аларның теләген хуплады һәм киләчәктә дә хәрбиләр турында кайгыртучанлык күрсәтеләчәге турында ышандырды.

Тормыш - икътисад кормыш?

Казан вузларында документлар кабул итү азагына якынлашып килә. Иң зур конкурс КДУның юридик һәм икътисад факультетларында, икътисад белән бәйләнешле уку йортларында: бер урынга алты гариза. Технология һәм техник университетларда (элеккеге КХТИ һәм КАИ) конкурс зур булырга ошамаган.

ТИҮдә шундый хәлләр

Редакциягә ТИҮнең гадәттән тыш пленумы үтүе турында хәбәр килде. Анда милли хәрәкәттә килеп чыккан кризистан чыгу юлларының тикшерелүе һәм бу уңайдан "моңа чаклы ТИҮ Уставын һәм III Корылтай карарларын бозган" М.Мөлеков һәм аның бер төркем тарафдарларының пленумда катнашудан баш тартулары турында әйтелә. Белдерүдән күренгәнчә, ТИҮнең элеккеге составы таратылган һәм яңа Президиум сайланган. ТИҮ рәисе вәкаләтләре юрист Н.Сафинга йөкләнгән. Бу вакыйга уңаеннан бүген көндезге ике сәгатьтә журналистлар өчен газета-журналлар нәшриятында матбугат конференциясе үткәреләчәк.

Бу арада "Т.Я."не ай саен әшкереп, укучыларыбызга шифалы газета бүләк итүче халык табибы Сания Мингалиеваны сорап шалтыратучылар күбәеп китте. Бу уңайдан шуны хәбәр итәбез: Сания ханым августка кадәр Актаныш, Зәй районнарында командировкада булачак. Күрергә теләүчеләр аны Актаныш районының Иске Кормаш авылыннан сорашып таба алалар.

Бер хәбәр уңаеннан

Ул һаман да шул Фәйзи

Татарстанның легендар колхоз рәисе Фәйзи (Фәйзрахман) Галиев пенсиягә чыкты. 19 яшеннән рәислек итә башлаган авыл малае 49 ел дәвамында нинди генә "борылыш" һәм "үзгәртеп кору"ларны күрмәгәндер. Ләкин аны легендар Фәйзи иткән сыйфат - гадилек һәм кешелеклелек. Үзе икмәк игеп туйганчы икмәк ашый алган, сәламәтлеген кайгырткан, газлы, юллы колхоз кешеләре өчен чал чәчле Фәйзрахман бүген дә кул җитмәслек рухи җитәкче булып кала бирә. Шуңа да аны үз халкы да, республика җитәкчеләре дә бердәй ярата, хөрмәтли. Ялга китүе уңаеннан Фәйзи аганы Татарстан Президенты М.Шәймиев үзе котлады. Аерым шәхескә юлланган мондый котлауны беренче булып Фәйзи ага алды.

Без дә яратабыз Фәйзи аганы. Үзен белгәннән бирле "Татарстан яшьләре"н алдырганы өчен генә түгел, әлбәттә. Аның җиргә бирелеп эшләүче зыялы булуы өчен, һәрвакыт яшьләрчә фикерләве өчен һәм, гомумән, Фәйзи Галиев булып калганы өчен. Озын-озак еллар сөенеп яшәргә язсын сиңа, җир улы!

Табиблар игътибарына

Ислам медицинасы болай ди

Ислам табибларының "Шифа" берләшмәсе табибларның белемен камилләштерү максатында махсус-практик Ислам медицинасы укулары уздыра. Анда Согуд Гәрәбстаныннан килгән табиблар Ислам медицинасы, Ислам мәдәнияты, Ислам дине нигезләре һәм гарәб теленнән белемнәр бирәчәкләр. Укулар Казан тирәсендәге ял базасында 2-8 августта бер атна дәвамында узачак.

Анда белемен камилләштерергә теләгән Ислам белән кызыксынучы табиблар, медицина институты студентлары катнаша ала. Укулар бушлай. Катнашырга теләүчеләр 19 июльгә кадәр шушы адреска мөрәҗәгать итә алалар: 420012. Казан а/я 30 Ислам табибларының "Шифа" берләшмәсе.

Телефоннар: 76-64-37, 36-46-25.



Табигать боерыкларга буйсынмый

Мәктәпләрдә укулар тәмамланып, балалар да, укытучы-тәрбиячеләр дә җәйге ялга чыкканга шактый вакыт узды. Яшь табигать сөючеләр хәзер күп гомерләрен һавада үткәрәләр - урман-кырлар, елга-күлләр алар карамагында. Ә менә алар табигатьне саклау буенча берәр төрле файдалы эш башкаралар микән? Әгәр "Т.Я."нең һәр санын күзәтеп барсалар, укучылар да, укытучылар да үзләрен каникулда итеп тоймаячаклар, ә бәлки үзләре аяк басып йөргән һәр адым җирне матур тоту, чистарту, саклау өчен тырышачаклар. Күпләр район мәгариф бүлекләренә, мәктәп директорларына Татарстан Халык мәгарифе министрлыгының "Кырмыска" конкурсында катнашуын тәэмин итәргә кушкан махсус боерыгын көтеп утырмадылар, конкрет эшкә тотындылар инде. Кичә генә редакциягә Казанның Абдулла Алиш исемендәге Балалар Үзәгенең экология бүлеге мөдире Илдар Җамалетдинов килде. Моңарчы бу Үзәк республика күләмендәге мондый конкурсларны үзе үткәрә торган иде. Ә быел алар үзләре дә шушы "Кырмыска" конкурсына катнашып, экспедицияләр оештырырга теләк белдерәләр. Борис Омилаев җитәкчелегендәге 12 кешелек группа алты көнлек экспедициягә чыгып киткән инде. Алар арасында Казанның 115, 113, 71 нче мәктәп укучылары, экология лицееннан ике кыз бар. Бу группа Зөя елгасына коя торган Үләмә елгасы буйлап тикшерү үткәрү өчен Тәтеш районын сайлап алган. Алар елганың санитария-саклау зонасына кергән терлекчелек фермаларын, җәйге лагерьларны карап, гаепләрне ачыклау һәм кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрү белән шөгыльләнәчәкләр.

Шушы көннәрдә Илдар Җамалетдинов үзе 15 бала белән Лениногорск якларына чыгып китәчәк. Алар анда бораулау скважиналарыннан җир асты суларын үлчәү үткәрәчәкләр. Бу эшне укучылар көнгә өч мәртәбә башкарачаклар.

Тәтеш, Лениногорск якларына Казан мәктәпләре укучылары ярдәмгә килгәндә, бу районнарда яшәүче балалар да үз төбәкләре табигатенә битараф калмаслар, алар да безгә нинди эшләр башкарулары турында хәбәр итәрләр дип ышанабыз.

Кызганычка каршы, республикабызның күп район мәгариф бүлекләре, мәктәпләре табигатьне саклау буенча эш җәелдерүләрен хәбәр итәргә бик ашыкмыйлар. Әллә чыннан да министрлыктан боерык килгәнне көтеп яталармы? Ләкин бит табигать бернинди дә боерыкларга буйсынмый. Нидер көтсәк, соңга калуыбыз ихтимал...

Һәр адымыбызны зур-зур этләр белән оманнар саклый. Әйтерсең без тоткыннар

Исәнме, лагерь! Биек наратлар арасына сыенган "Идел" халыкара яшьләр туристик лагерена килеп җитүгә, хәтеремдә II Бөтендөнья татар яшьләре көннәре яңарды. Их, ничек күңелле булган иде ул чакта! Без яшәгән бүлмә менә шушы йортта, ә монда таң атканчы кичке уеннар уза иде, әнә ашханә, кичке аштан соң анда концертлар, дискотека була, ә алда магърур Идел... Ә һавасы... һавасы гына да ни тора бит! Шәһәр ыгы-зыгысыннан табигатьнең шушы гүзәл почмагына килеп төшүгә күңелем күтәрелде, җиңел булып китте. Таш түшәлгән юлдан йөгерә-сикерә алга, лагерь эченә атладым...

Болай артык үзгәрешләр күренми. Тик тирә-яктагы тынлык кына бераз сәеррәк. Өченче ел кая карасаң да кеше була торган иде. Хәер, ул елны монда 380 ләп кеше ял итте, ә быел, әйтүләренә караганда, 100 гә якын җыелган. Путевканың 25 мең торуы бөтен кесәгә дә ярамый шул. Ә шулай да кайда соң халык? Идел буендадыр инде.

Элек монда көннәр бик җанлы үтә, вакыт минутына хәтле санаулы була торган иде. Быел лагерь тормышы ничегрәк икән? Әнә түбәтәйле бер егет килә, янына барыйм әле.

Беренче танышым Тәлгать Хәсәнов белән әнә шулай сөйләшеп киттек. Ул Самара университетының юридик факультеты студенты булу белән бергә, андагы "Туган тел" татар иҗтимагый үзәгенең әгъзасы да икән. Бирегә инде өченче ел рәттән килүе. Быел үзе белән сеңелесен дә алып килгән. Тәлгать быелгы лагерьдан алган беренче тәэсирләре, кичерешләре турында ашыга-ашыга сөйләп китте.

Быел программа ярлырак, - диде ул. - Шуңа күрә комда кызынырга, Иделдә су коенырга вакыт муеннан. Аннан соң, беренче көнне үк лагерь җитәкчеләренең салкын карашы зур канәгатьсезлек тудырды. Ышанасыңмы, безнең һәр адымыбызны зур-зур этләр белән омоннар саклый. Әйтерсең без тоткыннар. Әле беренче көнне үк иптәш егетем һәм бер кыз белән Идел буендагы атынчыкта утыра идек, яныбызга лагерь начальнигы һәм өч омонлы килеп чыкты. Шунда ук юкка-барга бәйләнә дә башладылар. Имеш, кич белән монда йөрергә, гомумән, атынчыкка утырырга ярамый, Татарстанда гадәттән тыш хәл икән. Ә без аны каян белик? Әгәр мин Самарадан, хәләл акчаларымны түләп, ял итәргә дип килгәнмен икән, нигә мин шушы җәйге кичләрдә уникe тулганчы ук ятып йокларга тиеш? Без берәүгә дә зыян китермибез бит. Кичләрен дискотекага якын-тирәдән исерек егетләр килә, аларга бер сүз әйтүче дә юк. Ә ял итәргә җыелган яшьләрнең һәр адымын этләр белән саклау лагерь тормышына тискәре йогынты ясый.

- Ә көннәр ничек үтә?

- Гомумән алганда, күңелле үтә. Яхшы ашаталар, ял итүчеләргә әйбәт хезмәт күрсәтәләр, бирегә җыелган яшьләр үзара тату, бердәм яшиләр. Тик шул ирегебезне кысу ачуны китерә.

... Соңыннан "Т.Я." уздырган очрашуда да бу турыда сүз күп булды. Кемнеңдер аягын эт тешләгән, кайсындыр куркыткан... Пляжда зур-зур этләрнең иркенләп йөрүе дә бераз шикләндерә. Хәер, ял итүчеләр аларга ияләнеп килә бугай инде. Әнә бер Изаура исемле әнчек белән кечкенә малайлар мәш килә. Бергә су коеналар, йөгерешәләр... Мондагы иркенлек, хозурлык һәркемгә җитә, дип уйлап куйдым. Күңелгә үзеннән-үзе әнием көйләп йөргән җыр килә:

Идел бит ул, тирән бит ул,
Идел бит ул, киң бит ул...

Их, рәхәт! Тән, күңел, уйлар ял итә. Нинди гүзәл табигатебез, нинди байлыкларыбыз бар бит! Йөгереп Иделгә кереп китәм... Менә мин муенчма хәтле Идел суында басып торам. Тирә якта чиксез су дәрьясы. Бу ярда нарат урманы, ә каршыда мәһабәт таулар куенына сыенган авыллар. Шушы гүзәл җирнең баласы булуыма сөенеп, горурланып куйдым.Баһасез байлыкларыбызга лаеклы хуҗа була белсәк иде. Әнә бер үлгән балык йөзеп килә. Нигә үлгән? Иделдә үлгән балыклар күп диләр...

...Танышларым көймәдә йөзәргә чакырдылар. Иделдә көймәдә йөзгән юк әле, шатланып риза булдым. Дөрес, теплоходта шәһре Болгарга барган идек. Ул сәяхәт онытылмаслык хатирә булып калды. Болгарга бару татар яшьләре көннәренең гүзәл традициясенә әйләнде.

... Бер төркем яшьләр уртасында озын чәчле берәү гитара белән җырлап утыра иде. Инглизчә, чегәнчә, русча, татарча җырлавына соклanырлык. Үзе дә җырлар яза икән, заманча татар җырлары. Баксаң, берничә елдан бирле татарча дискотекаларда җырларына биеп йөргән Ильяс Вәлишев үзе икән бит! Җырлары күптән таныш булса да, үзен күргәнем юк иде. Бигрәк тыйнак, гади егет булып чыкты. Екатеринбургтан инде безгә яхшы таныш Хәйдәр Гыйльфанов та гаиләсе белән бирегә ял итәргә килгән. Лагерьда Екатеринбург делегациясе концерты оештырып йөриләр. Менә бит Татарстаннан читтә нинди милләттәшләребез яши!

"Идел"гә кунакка "Айфара" группасы килгән. Кичке аштан соң аларның чыгышы башланды. Рәхәтләндек биеп! Чит төбәкләрдә яшәүчеләрнең күбесе әлеге группа белән таныш түгел әле. Ә бу көнне "Айфара" егетләре үзләренә бик күп яңа дуслар таптылар. Дискотека уникенче яртыда тәмамланды. Яшьләр биеп туямыни?! Ә лагерьда төнге уникедә тынлык булырга тиеш. Югыйсә, хәзер бозау хәтле этләрен ияртеп тәртип саклаучылар килеп җитәчәк. Яшьләр гармун белән лагерь тупрагыннан читкә, кичке уенга юнәлделәр... Җәйге төннәр кыска бит, тиздән таң атар. Татар яшьләре көннәрендә елның елында таңнар шулай ата: җыр-бию белән...

Миләүшә БИЛАЛОВА.

IV Бөтендөнья татар яшьләре көннәре көндәлеге

27 июнь - Төрле төбәкләрдән җыелган яшьләрнең лагерьга урнашу көне, танышу кичәсе. Дискотека.

28 июнь - Ачылу тантанасы.

29 июнь - Шәһре Болгарга сәяхәт.

30 июнь - Дин әһелләре белән очрашу, дин дәресләре. Әдәбият һәм тарих темасына лекция. Юмор кичәсе.

1 июль - Дин дәресләре. "Татарстан яшьләре" газетасы журналистлары белән очрашу.

2 июль - Казанга бару, мәчетләрдә, татар зиратында булу, Кабан арты мәчетендә - җомга намазы. "Айфара" группасы концерты.

3-4 июль - "Мәгърифәт" газетасы көннәре. Яшь җырчы Нурәхмәт Мөхәммәтҗанов катнашында редакция хезмәткәрләре белән очрашу кичәсе. Спорт ярышлары.

5 июль - Татар яшьләре проблемалары буенча конференция.

6 июль - Казанга экскурсия. Сабантуйга бирнә җыю.

7 июль - Сабантуй.

8 июль - IV Бөтендөнья татар яшьләре көннәренең ябылуы.

Ун көн эчендә бер-берсе белән "туганлашып" беткән яшьләр үз өйләренә таралышалар. Бу көннәрдә сузылган дуслык җепләре буенча илебезнең төрле шәһәрләре арасында шактый хатлар йөрер әле.


Кыскача көндәлек шундый. Лагерьда үткән көннәр белән чагыштырганда, без язган кадәрлесе, әлбәттә, коры сөяк кенә. Көн саен дискотекадан соң таң атканчы кичке уендагы җыр-биюләрне, көннең теләсә кайсы вакытында бергәләп Иделдә су керү, көймәләрдә йөзү, гитара белән җырлап утыру дисеңме,... И-и, аларны язып бетерерлекмени?! Шуны әйтә алабыз, бу көннәр һәркем өчен яшьлекнең онытылмаслык якты мизгелләре булып калачак.



Кеше күңеле киң. Аның зур эш башкарган саен тагын да зуррагына тотынасы килә башлый. Кечкенә генә мисал: "Т.Я." "Идел" лагерена барып яшьләр белән кыска вакытлы очрашу оештырып кайткач (өстәге рәсемдә) янә бер барып бөтен лагерьне аякка бастырып кайтты. Ә IV Бөтендөнья татар яшьләре көннәре уйланырга мәҗбүр итте, чишеләсе бик күп мәсьәләләрне күрсәтте. Алар турында алга таба сөйләшү булыр әле. Ә бүгенгә - лагерьдан репортаж.

Евгений КАНАЕВ фотолары.







13нче БАГАНА

"Т.Я."да Балтач районында яшәүче бер кызның инвалид коляскасы сорап язган хатын укыган идек. Без аңа булыша алабыз.

Марат ГАРИФУЛЛИН.
Чистай районы, Татар Талкышы авылы.

Редакциядән. *Марат, кешелеклегең, изгелегең, мәрхәмәтең өчен зур рәхмәт. Синең кебек шәфкатьле кешеләр табылды, алар Балтач кызы Чулпанга инвалид коляскасы алуда ярдәм иттеләр.*

* * *

Безнең авылга Искәндәр Биктаһиров үзенең концерт бригадасы белән килде. Күптән инде авылыбызда шундый концертларның булганы юк иде. Районыбызның сирәк авылларына әлегә мондый бәхет. Рәхмәт, Искәндәр дус. Синең белән тагын очрашырга язсын. Һәм, әлбәттә, аякларың җиңел булсын, бүтән артистлар да тагын килсен иде безгә.

Хәлим АЛИМОВ.
Октябрь районы, Зирекле авылы.

* * *

Мин быел беренче тапкыр Арчага Сабантуйга бардым. Татарстанда андый матур Сабантуйны күргән юк иде әле. Көн яңгырлы иде, шулай да кеше өйгә таралырга ашыкмады. Анда Президент Шәймиев тә бар иде шул. Тере Президентны кайда күргән булыр идем әле!

Шушында ук яраткан артистым Салават Фәтхетдиновны да күрдем бит. Аның белән очрашу үзе ни тора. Самолетлар, вертолетлар очышы, атлар чабышы, көрәшчеләр бәйгесе дә бик күңелле, кызыклы иде, әлбәттә. Әмма татарның шундый күренекле шәхесләре белән бер мәйданда йөрүдән, бер яңгыр астында чыланудан да бәхетлесе юктыр кебек тоелды. Сабантуйның саф татарча алып барылуы икенче бер милли горурлык булды миңа.

Ленара ДӘҮЛӘТХАНОВА.
Киров өлкәсе, Красная поляна авылы.

* * *

Ниһаять, яңа Татарстан картасы кибетләргә чыкты. Шунысы бик күңелле: картаның бер читенә үзебезнең гербыбыз - барс сурәте ясалган. Аннары, зурмы-кечкенәме, теләсә кайсы авылны табып була. Татарстан чигендәге күрше республикалар һәм өлкәләрнең торак пунктлары, хәтта зур шәһәрләр дә сыйган бу картага. Чабаксар, Йошкар-Ола, Ульяновскидан тыш, мин анда үземнең туган авылымны - Башкортостанның Баулыга чиктәш Ярмәкәй районындагы Усман-Ташлыны да таптым. Тик картаның тиражы бик кечкенә - нибары 100 мең.

З.ЙОСЫПОВ.
Казан.

ЯЗУЧЫ БУЛАСЫҢ КИЛСӘ...

Кадерле редакция!
Әткәй дә, әнкәй дә мине язучы итәргә маташалар. Көн саен әйткәләшеп тә алалар. Берсе әйтә: "Балалар язучысы булсын! Аның өчен акыл кирәкми", - ди. Икенчесе: "Драматург итем. Кешеләрнең сөйләшкәнен, таланкаларын теркәп кенә йөрер", - ди. Романчы да, сатирик та итмәкчеләр, шагыйрь дә ясамакчылар... Мин үзем әлегә хат та яза белмим. Шулай да, ныклап мәҗбүр итсәләр, нинди язучы булырга икән?

Роберт МӨХӘММӘДИЕВ,
VI сыйныф укучысы,
Самара өлкәсе.

РЕДАКЦИЯДӘН. Укучыбызның хатына тәфсилле җавап бирүен сорап, сатирик язучы Фәнзаман Батталга мөрәҗәгать иттек. Ул каршы килмәде, берничә киңәшен бирде.

Кереш сүз

И, исәнме киләчәкнең бөек язучысы, Роберт энекәш! Исем-фамилияңне күрү белән синең язучы булырыңа шигем калмады. Чөнки барысын да исем-фамилия хәл итә. Әйтик, шундый исемең бар икән, күңелеңә шик тә килмәскә тиеш. Бармакларыңны бөгә-бөгә саный тор: Роберт Батулла, Роберт Миңнуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Роберт Рәкыйпов... Әле тагын егермеләп Роберт гәзит-журналларда шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр бастыргалап тора. Әтиеңнең исеме, алай-болай, Рәшит, Гәрәй яки Вәли, Әхмәт яки Камал түгелме? Шуларның берсе туры килсә, язучы булу өчен мөмкинлегең тагын да арта диган сүз. Әйтик: Рәшит Гәрәй, Гәрәй Рәхим, Салисә Гәрәева, Рәшит Әхмәтҗанов, Әхмәт Рәшитов, Рәшит Ахунов, Рәшит Бәшәр. Күрдеңме инде, аллә ничәшәр! Вәлиевләрнең күзгә күренгәне генә дистәдән арта. Камалларны әйткән дә юк - бер вагон.

Инде синең дә шигең калмагандыр: төп хикмәт исемдә! Шулай итеп, бер дә икеләнмичә теләсә нинди әсәрне яз да ташла. Ә инде хат язарга соңрак та өйрәнерсең.

Беренче киңәш

Әлбәттә, бала кешегә иң әйбәте балалар язучысы булу. Бигрәк тә балалар шагыйре. Чөнки шигырьдә рифма диган кәлтифүн була. "Куян" диюгә үк "куам", "суям" яки "куям" диясе килә. Баксаң, бер сулышта шигырь язылып та беткән:

Урманнан чыга куян,
Мин аңа капкын куям.
Үзем артыннан куам,
Тоткач "кых" итәм - суям.
Колагына кирт уям,
Итен ашасам - туям.

Ләкин балалар язучысы булу өчен гомер буе балалар холкы белән яшәргә кирәк. Беренче шарты: нәрсә әйтсәләр - шуңа ышанырга. Әйтик, өстәге агайлар октябрь ае гына шәп ай дисәләр, икеләнмичә яз да куй:

Һәрбер халык беркөн үз бәйрәмен -
Үз Октябрен яулар - күрерсез.

Әгәренки дә җирдәге халыклар үз июнен, июлен, августын яулап, башка айларда да бәйрәм итә башласалар һәм син шуны үз күзләрең белән күрсәң, аптырап торма - тәртәне кирегә борып, бөтенләй икенче нәрсә яза башла. Ләкин аң бул: зурлар хуплаганны, бүгенге көн кушканны куәтлә. Дин көчәя диләр икән, дога турында шигырь язу отышлы.

Дога дигәннән, балалар шагыйрьләренең әнкәләре доганы күп укучан була. Булачак шагыйрьне Сөннән яки Иделдән алып кайта да дога укырга керешә. Кайберләре кәбестә, шалкан арасыннан да, коедан да алып кайта киләчәк шагыйрен.

Кайдан гына алып кайтмасыннар, син үҗәт булырга тиеш. Бер кешедән дә калышма! Берәр җиргә начальник кирәклеген күрсәң: "Менә мин ул!" - диген. Әгәр илдә депутатлар сайлау башлана икән, соңга калма - йөгер, депутат булырга тырыш.

Балалар язучысы депутат итеп сайланса, аңа берчакта да зур таләп куймыйлар. Чөнки бала итеп карыйлар. Сессияләрдә сөйләргә кушмыйлар, сөйләр сүзе юклыгын күзеннән үк күреп торалар. Депутат шагыйрь (шагыйрь депутат дисәк тә ярый) сессиядә дә куяннар, төлкеләр, тараканнар, балыклар турында гына уйлап утыра. Башкалар кызып-кызып Татарстанның азатлыгын куәтлиләр, ә бу күз алдына, хыялына килгән куянның йөгерүенә елмаеп утыра. Тик шунысы: Татарстан барсы бер якка бара, моның куяны кире якка чаба.

Депутат исемен дә алган балалар шагыйренең кул астына кайчак нинди дә булса карар яки башка документ тыгалар. Фаразан, әлеге документка болай дип язылган: "Татарстан Папуасстан референдумында катнашырга тиешме?" Шагыйрь кул куя. Ни өчен дисәң, папуаслар, маймыл койрыгына тотынып, пальмалар өстендә атынып йөриләр. Дөрес, кайберәүләр мондый депутатны сүгәләр, каргыйлар. Имеш, Татарстан - үз юлында, Папуасстан үз кыйбласында булырга тиеш, диләр. Теге кәгазьгә кулны да үз башы белән уйлап куйган дип беләләр һәм... нәкъ шунда ялгышалар да! Чөнки әлеге депутат аны үз белдеге белән куймаган, үзеннән өстәгеләр кушканга куйган. Нишләмәк кирәк, балалар шагыйре, кырыкта-илледә-алтмышта-җитмештә булса да сабый шикелле тыңлаучан булырга тиештер.

Игътибар иткәнең бармы, Роберт энем: кайбер балалар кәнфит яки уенчык өләшкәннәргә беренче булып ыргылалар. Үсә-үсә балалар шагыйре булып җиткән кайбер абыеңа да һәркайда кәнфит өләшәләрдер, ул гына өлешсез каладыр сыман тоела. Йә Тукай премиясенә кул суза ул, яки көн саен телевизордан күренергә тырыша...

Кыскасы, балалар шагыйре буласың килсә, алда ук әйткәнемчә, бала гадәтең калсын. Нинди генә юньле нәрсә яки яхшы урын күрсәтсәләр дә өздереп-кистереп: "Миңа!!!" - диген. Бирмирәк торсалар, авызыңны күтәреп, мыекларыңны тырпайтып ела. Аякларыңны тыпырдата-тыпырдата, бии-бии ела! Вәйт, булырсың шагыйрь!..

Икенче киңәш

Фамилияңә карагандa, син романчы булырга тиеш. Ягъни, зурлар-өлкәннәр язучысы... Ләкин шәйлә: бу очракта син үзең дә һәрьяктан зур күренергә, зурларча кыланырга тиеш. Зур булып күренү өчен, хәлеңнән киләме-юкмы, зурлар яки бөекләр турында яз. Чөнки бөтен дөнья әлеге бөекне мактап торганда синең фамилияң дә пүчтәк булып тоелмаячак. Ни дисәң дә, фамилияләрегез бер китапта басылачак. Бу очракта инде куян белән генә беркая да бара алмыйсың. Арсланнар, аюлар кебек абзыйлар тирәсендә чуалырга кирәк. Әйтик, әледән-әле кушаяклап Ельцин янына йөгерәсең:

- Татарстан синнән башка яши алмый, Борис дәдәй. Мин сиңа Ватанымны да бушлай бирәм, - дисең. Ә Ельцин сиңа күн пәлтәләр, машиналар бүләк итәр... Яхшы кунакханәләрдәге люкс номерларда йоклатыр, Мәскәүдән дә фатир бирәм дип торыр, кесәңне акча белән тутырыр. Казанга кайткан саен икенче сүзне куерт. "Мин Татарстан азатлыгы өчен тырышам", - диген. Монда да иң әйбәт фатир синеке булыр, Тукай премиясе бирерләр. Илләдә мәгәр шома күрен. Карашың да гөнаһсыз тоелсын.

Минем шушы киңәшем белән яшәүче абыйларының берсе, мәсәлән, бик зур кеше булып җитеште. Янында һәрвакыт аның җырын җырлаучылар кайнаша. И, мактыйлар тегене, күккә чөяләр (көне җиткәнче), аның белән бергә "Әшнәя" диган карусельдә әйләнәләр (төртеп төшергәнче), күзенә карап елмаялар (соңыннан мыскыллап көлгәнче). карусельдән төшкәч, теркелдәп артыннан йөгерәләр (аяк чалып аударыр сәгать сукканчы)...

Башка төрлерәк романчы булсаң, алдан сагай. Хәзер үк кисәтеп куям: романыңның исемен сорау билгесе белән куйма. Алай-болай "Таяк кем кулында?" дигән исем кушсаң, башка язучылар өстеңә ыргылачаклар. "Таяк үз кулындадыр әле, безне кыйнарга әзерләнәдер!" - дип, тетмәңне тетәчәкләр. Китабыңның тышына "Сезнеңчә ничек?" дигән сорауны да язма. Бу якын тирәдәгеләрнең котын алачак. "Туктале, мондый сорау бирә белгәч, моның үз фикере дә бардыр," - дип, шик белән караячаклар. Шуннан соң инде син күн пәлтәле абыйларыңнан мең мәртәбә шәбрәк язсаң да, Тукай премиясен төшеңдә дә күрмәячәксең. Чөнки бу милләтнең җитәкчеләре үз фикере, үз башы булган затны яратмыйлар.

Премия дигәннән, "Әшнәя" каруселендә сәйран кылучы абзыйларыңны да күрмәгәнгә салыш. Әгәр дә мәгәр син:

- Нишләп ул карусельдә үзегез генә әйләнәсез? - дип үпкә белдерсәң, бүләк яки премия түгел, гомереңбуена җылы сүз дә ишетмәячәксең.

Өченче киңәш

Юмор яки сатира язучы абзыйларың, Роберт энем, үскәндә үк үзенчәлекле шартларда үсәргә тиешләр. Аларны бәләкәй чакта ук, усал телле булган өчен, кычыткан белән пешекләп торалар. Шыр кычкырып, үрле-кырлы сикерә киләчәкнең сатирыгы!.. Яшелле-зәңгәрле тавышлар белән сөрән сала. Шунда кемгә дә булса каршы әйтергә дә өлгерә, авызын чүмкәйтеп, үчекләп тә ала. Минем бер дус сатирикны, мәсәлән, малай чагында тешсез агай тотып ярган.

- Фин нәрфә, тифек борын, безнең кар базына төфеп, фөт өфтен урлап йөрифең?! - ди-ди ут өертә икән тегене. Шуннан соң теге малай үсә, язарга өйрәнә һәм, тешсез агайга үч итеп, тешсезләрне мыскыл иткән хикәят яза.

Сатириклар үскәндә үк көнче булалар. Әйтик, үзе үскәндә икенче бер малайны еф-еф итеп, кадерләп үстерәләр икән, көт тә тор: шулчакта көнчелектән үләрдәй булып яшәгән малай, кулына каләм алуга ук, кадер-хөрмәттә үскән иптәшеннән көлеп язачак!..

Төртмә телләре аркасында, булачак сатирик язучылар әти-әниләре тарафыннан да, башкалардан да назлы сүз ишетмиләр. Ничек кенә тырыш булсалар да, аларга рәхмәт әйтүче дә, башларыннан сыйпаучы да булмый. Кем теләсә, шул типкәли. Үскәч тә шулай: каләмдәшләре кыерсыта, җитәкчеләре кыйный, патшалар, президентлар сөйми... Ләкин, шунысы гаҗәп, сатирикларның берчакта да кәефләре кырылмый: кыйналган саен елмаялар, суккан саен көләләр, көр күңел белән яшиләр.

Шуңа күрә, Роберт энем, үзең шәйлә: гомер буе типкедә яшисең килсә генә сатирик язучы булырга тырыш. Башта сыек чыбык белән кычыткан ашарсың, аннан соң шымытыр белән тамак туйдырырсың. Шымытыр чәйнәгәндә шырык-шырык көләрсең...

Дүртенче киңәш

Кулыңнан башка жанр чыкмаса, тәнкыйтьче булып китүең ихтимал. Күргәнең бардыр, кайбер абыйларының хикәясе, романы түгел, шигыре дә юк. Ә үзләре, барыбер, язучы дигән исемне йөртәләр. Аларның китап-китап язган язуларының мәгънәсе бер җөмләгә сыеп бетә: "Фәлән язучының романы пешеп җитмәгән. Төгән шагыйрь уңышлы рифмалар тапмаган..."

Алар инде көнченең дә көнчесе! Чөнки үзләре дә иң әүвәл шигырь язып караганнар. "Кара-бара, урман-чытырман, алма-салма, керәшен-керәсең" сыманрак сүзләр белән уйнап-уйнап та фәтвә чыкмагач, хикәя язырга тырышып көчәнгәннәр. Анысы да кулдан килмәгәч, булачак тәнкыйтьчеләр берничә ел авыз бүлтәйтеп, тынсыз калып йөриләр. Ә язучы булу дәрте бетмәгән әле, бетмәгән!.. Шуннан соң тотына болар бүтән язучылардан үч алырга. Нинди генә китапны укысалар да гаеп эзлиләр. Әгәренки берәр язучы: "Нәфисә урманнан чыкты..." дип яза икән, тәнкыйтьче Нәфисәне дә, урманны да, керде-чыктыны да шик астына ала. Ягъни: урманга ни өчен барган, кем белән барган, анда нишләгән, ни өчен әрәмәлектә түгел, урманда йөргән, аннан ни өчен берүзе чыккан? Кайсыдыр язучы: "Фәхри башын кашып алды", - дигән җөмлә язып куйса - бетте! - тәнкыйтьче шундук эләктереп ала: "Фәлән әдип коммунизм төзүче Фәхринең образын кара буяулар белән сурәтләгән, аның бетле булырга тиешлегенә ишарә ясаган. Аннан, шунысы да бар, коммунизм төзүчеләрнең баш кашырга түгел, күт кашырга да вакытлары булмаска тиеш".

Күрдеңме инде, **Роберт** энекәш, тәнкыйтьчеләргә берничек тә ярый алмыйсың. Алар гомерләре буе чын язучыларга кырын карыйлар, аяк чалырга, үч алырга тырышалар. Шунлыктан көяләр, ябыгалар, ашаган ипиләрен дә файдалы итеп сеңдерүдән гаҗиз булып гомер кичерәләр.

Ахыргы киңәш

Дөресен генә әйткәндә, Роберт энем, башка каләм ияләренә дә йон кунмый - алары да ачлы-туклы яши. Чирлелектән яки сәламәтсезлектән түгел моның сәбәбе - хәерчелектән. Чөнки җир йөзендә иң кадерсез, иң хәерче, иң фәкыйрь язучылар - татар язучылары. Үзең исәпләп кара: татар язучысының еллар буе язган китабына кенгә ике-өч сәгать кенә идән юып, "уборщица" булып яшәүче гарип әбиеңнең айлык хезмәт хакын гына бирәләр. Татар язучысы урыслар өчен чучка симертүче дуңгыз караучыдан 10 мәртәбә (!) азрак ала. Татар язучысы урамда хәер сорашучы хәерчедән дә күп мәртәбә мескенрәк.

- Ни өчен? - дип сорый калсаң, хикмәте болай: үзең күрәсең, татар язучылары Татарстанның мөстәкыйльлеккә, азатлыкка ирешүен теләп, күп яздылар. Яза торгач, халыкка да үз фикерләрен сеңдереп бетерделәр. Шуннан соң халык Татарстан башлыкларын азатлыкка таба әйдәкләргә керешә. Алдан тарта торгач, арттан этә торгач, безнең дәү җитәкчеләр үзләре теләмәгән мөстәкыйльлек капкасына килеп терәлделәр. Хәзер алар аптырашта: капкадан керерләр иде, Ельцин дәдәйдән куркалар, керми торырлар иде, язучылар фикерен туплаган татар халкы арттан кыса.

Менә шуның өчен дә Татарстан хакимияте әдипләрдән үч ала. Янасе: "Тырышкан идегезме?! Инде җәфасын, михнәтен үзегез күрегез, йә булмаса, халыкның мөстәкыйльлектән кирегә әйдәгез!" Алай түгелдер, дип әйтә алмыйсың, Роберт энем. Ни өчен дигәндә, мөстәкыйльлекне яулау турында уйламаган Башкортостан язучылары да мөстәкыйль Татарстан язучыларыннан ике мәртәбә күбрәк акча ала.

Күрәмсең, Ельцин абыең да шылтыратып торадыр: "Язучыларыгызның булганнары үлсен, яңалары язарга җөрьәт итмәсен! - дип.


Әле шунысын да белеп тор: Татарстан җитәкчеләре татар әдәбиятын укымый. Сөйләшүләре дә: "Хөрмәтле көн, хәерле иптәшләр" чамасында гына...

Кыскасы, энем, хәзерге хакимият татар әдәбиятын (димәк, татар телен дә!) бетерү өстендә эшли. Шуңа күрә язучы булырга тырышма, кулыңа каләм алма. Минем киңәшкә ышанмасаң, Тукай абыеңның сүзен тот. Ул болай дигән:

Сиңа, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат,
Тырактир ач татарга, - сат та тор һәртөрле мәшрубат.

Тырактиры - пивнушка яки рюмочный, ә мәшрубаты - төрле су, хәмер диган сүз. Дөрес әйткән шул: хәмер сатучылар инде миллионер, миллиардер булып беттеләр, ә татар язучылары тиздән ыштансыз йөриячәк. Шул көнгә каласың килсә, безнең сафка рәхим ит, энекәш, бергәләп атларбыз.

Фәнзаман БАТТАЛ.





Хәләл вә хәрәм ит

Нәрсә ул хәрәм ит? Мөселман суймаган ит сәламәтлек өчен дә зыянлы диләр? Дөресме шул? Берәр белгеч җавап бирсен әле?

МӘДӘНИЯ.
Чаллы.


Минем үземә дә нәкъ шушы сорауны еш бирәләр. Шуңа күрә бу хакта бераз аңлатып китүне максат иттем.

Ислам дине кануны хәрам ит ашауны хупламый. "Мөэмин-мөселман мөселманча шартын китереп (канын агызып) суелмаган ит ашаса акылы томаланыр" дип өйрәтә. Сер түгел, бүгенге көндә күпчелегебез кибеттән сатып алган ит ашый. Яхшырак очракта базардан, хуҗалыкта асралган мал итен ала. Ә инде шартын китереп сую ягына килгәндә, анысын ходай бар итсен. Ә ни өчен ит комбинатларында суелган ит зарарлы дилә? Физиологик яктан карап үтик әле. Эре мал, ягъни сыер үзенең суеласын ике көн алдан белеп тора һәм курку кичерә. Әгәр өстәвенә мал суючы дорфа да булса, ул тагын да курка, стресс кичәя. Ит комбинатына китерелгән маллар бирердәге атмосфераны тоеп, көчле стресс кичерәләр. Мондагы мал сую техникасы бу стрессны икеләтә арттыра. Ә инде көчле стресс алган организмдагы тискәре үзгәрешләрне санап бетергесез. Болар - кан тамырларына холестерин утыру, кан басымы арту, һ.б. Билгеле инде, көчле психоэмоциональ ярсытылып, авыр кичерешләргә дучар ителгән хайванның бөтен күзәнәкләрендә, кан тамырларында зарарлы актив матдәләр барлыкка килә. Менә шулар ризык аша кеше организмына да күчә һәм шул ук тискәре үзгәрешләрне китереп чыгара.

Бу уңайдан мөселманнарның мал сую йоласы бөтен ягын уйлап эш итүне күздә тота. Мал билгеле бер чиста урында кыйблага каратып чалына. Чалынасы малга кычкыру зур гөнаһ санала. Чалынасы малны иркәләп-сыйпап, аңа махсус догасын укыйлар. Чалганда яхшылап канын агызып бетерәләр. Шушы йолаларны җиренә җиткереп үтәгәндә, актив матдәләр кан белән агып бетә дип исәпләнә.

Ә соң симез генә сарык итен ашаучылар нигә артык зыян күрмиләр? Сыер үзен суясыларын ике көн алдан белә дигән идек. Сарык белми икән. Димәк, сарыкта сыердагы кебек көчле стресс булмый.

Сәмания ШӘРИПОВА,
табибә.



Мәскәүнең җир асты хәзер пассажирларны ташып кына калмый, ә бәяки ашата да. Пассажирларны ташу эшен метрополитен башкарса, ашату ягын Американың "Пепсико. ИНК" компаниясе җитәкчелегендәге чит ил эшкуарлары үз өсләренә алганнар. Метроның "Парк культуры" станциясендә инде беренче киоск та эшли. Нью-Йоркның кыздырылган тавык, сосискаларын, арпа оныннан пешерелгән коймакларны, эчемлекләрнең җанын теләгәнен татып караучылар да юк түгел. Америкалылар көн саен 9 миллион пассажирга хезмәт күрсәтергә һәм шуның белән бергә Мәскәүнең кимендә 6 мең кешесен яңа эш урыны белән тәэмин итәргә җыеналар.

Рәсемдә: Мәскәү метросында ачылган Американың беренче киоскы.

ТАСС фотосы.



Май аенда вокзалда Булат Хәсәнов исемле кешенең документларын (хәрби билет, паспорт, саклык кенәгәсе) таптым. Паспорттагы адрес буенча хат язган идем, җавап килмәде. Бәлкем, ул газетадан шушы белдерүне укыр.

Адрес: Татарстан, Балтач районы, В.Сосна авылы, Әхмәтхан ТАҖЕТДИНОВ.

* * *

Биектау районы, Урта Алат авылында яңа мәчет төзелә башлады. Бу изге эшкә сезнең мөмкин булган ярдәмегезгә өмет итеп калабыз.

Адрес: Татарстан, Биектау районы, Урта Алат авылы советы. Р/с 11130303, Дубъязский СХБ, кор/счет 700161925, МФО 265232.

* * *

Бавыр церрозын ничек дәвалауны белүчеләр юк микән? Хат көтәм.

Адрес: 423832, Татарстан, Яр Чаллы шәһәре, 39/07 йорт, 46 фатир. М.ШӘРӘПОВА.

* * *

Документы өчен йөрергә яраксыз хәлдә булган "Москвич - 400, 401, 407, 408, 412" автомашинасы сатып алам.

Адрес: Казан - 78, VII-КБ серияле, 607795 номерлы паспорт иясенә.

* * *

Газета аша "Тюрнясевский" , совхозында эшләүчеләргә чын күңелдән үземнең рәхмәтемне җиткерәсем килә.

Һадия ЯКУПОВА.

Булмас димә

Балалы булырга теләсәгез - джинсы кимәгез

Җәйләре аерылып китәрдәй булып тәнгә ябышып торучы һава кертми торган джинсылар ирләрне нәселсез калдыруга илтә дип раслый танылган поляк сексологы Михалина Вислоцкая. Кысып торучы эластик һәм йон плавкилар да шундый ук нәтиҗәгә китерә.

Эш шунда, сперматозоидлар эшләп чыгаручы күкәйләр тән температурасыннан 2-3 градуска түбән температурада гына нормаль эшлиләр. Шул рәвешле сперматозоидлар суыткычтагы кебек сакланалар һәм хәрәкәткә килмичә һәм энергия сарыф итмичә йокымсырыйлар.

Ә югарыда әйтелгән шартларда сперматозоидлар иртә уяналар һәм күкәйләрдә, орлык юлларында сәяхәт итә башлыйлар. Бу очракта алар лифтта күтәреләсе урында 16 катка җәяү менеп тыны кысылган кеше хәлендә булалар. Вакытыннан алда җылыну нәтиҗәсендә үзләренең көчен югалткан сперматозоидлар инде аталандыруга сәләтсез булып чыга.

Нәтиҗә бер генә: күлмәкыштан иркен булырга тиеш. Бу турыда балалы булырмын дип йөрүче ирләр исләреннән чыгармаска тиеш.

Ирләрне исенә карап яраталар

Күптән түгел генә Англиядәге бер парфюмерия компаниясе сораштыру үткәрде. Аннан күренгәнчә, сораштыруда катнашучыларның 71 проценты җенси сөйкемлелекнең төп факторын ис дип атады.

Хатын-кызлар моңа аеруча зур игътибар итәләр. Алар үзләренә партнер сайлаганда ирләрнең лосьон, дезодарант яки хушбуй сипкәннәренә тәкатьсез булуларын әйтәләр.

"Доверие" чек-инвестиция фонды

- **Фонд акцияләрен 1993 елның 1 маена кадәр алган гражданнарга быелның 20 июленнән аванс рәвешендә 200% еллык дивидентлар түләнә башлавы турында хәбәр итә.**
- **Сезнең ваучерларыгызны зур керемле дистәләгән оешмалар акцияләренә алмаштыра.**
- **Гражданнарның чекларын Татарстан Республикасы һәм Россиянең зур шәһәрләре (Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б.) күчемсез милкенә урнаштыра.**
- **Бер приватизация чегы фондның ун акциясенә алмаштырыла.**
- **Пенсионерлар, инвалидлар, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүчеләр регистрация өчен түләү бәясеннән азат ителәләр.**
- **Гражданнарның приватизация чекларын сатып ала.**
- **Фонд акцияләренә Татарстанның барлык почта бүлекләрендә 20 июльдән соң язылырга мөмкин.**
- **Белешмәләр алу өчен адрес: Казан шәһәре, Восстание урамы, 82 йорт, 226 бүлмә. Телефон: 42-59-04.**

Без сезнең ышанычыгыз өчен җаваплы.



Укучыларыбыз игътибарына!

1 июльдән танышу белдерүләрен бастыру бәяләре үзгәрде. Газетада танышу турында белдерү бастырып чыгару өчен редакция счетына 1000 сум, "номер"га хат язган өчен 500 сум күләмендә акча күчерергә һәм акча күчергәнлек турындагы квитанция белән хатны редакция адресына җибәрергә кирәк. Редакция "номер"ларга хатларны үзе тапшыра, ләкин аларның җавап хаты язуларын гарантияләми һәм адресларын хәбәр итми.

ИР-881

Мин үзем 1940 елгы. Үз өем белән авылда торам, мал-туар асрыйм. Колхозда эшлим. Аракы эчмим, тәмәке бераз тартам. Авылыбыз яшәү өчен уңайлы, газ кергән. Шушы ялгыз тормышта 50-55 яшьләр тирәсендәге үземә тиң кеше табылса, бик күп рәхмәтләр укыр идем.

ГР-883

Миңа 30 яшь, буем 173 см. Милләтем татар. Матди яктан һәм торак белән тәэмин ителгән. Югары белемле. Гаилә кору максатында 17-22 яшьләрдәге татар кызы белән танышырга телим.

ША-885

Миңа 22 яшь, буем 162 см. Урта белемле, өйләнмәгән татар егете. 25 яшькә кадәрле татар кызы белән танышырга телим. Килгән фотосурәтләрне кире кайтарам.

ХГ-887

Миңа 35 яшь, буем 165 см. Хатыным вафат булды. 4 һәм 9 яшьлек ике улым бар. Барлык уңайлыклары булган ике бүлмәле фатирда яшибез. Гаилә кору максатында, 29-38 яшьләрдәге, поселокта яшәргә риза булган хатын-кыз белән танышыр идем. Баласы булса да ярый.

АГ-889

Миңа 24 яшь. Өйләнгәнем булмады, начар гадәтләрем юк. Шәһәрдә үз йортымда яшим. Милләтем татар. Гаилә кору максатында 20-24 яшьләрдәге, буе 170 сантиметрдан артмаган татар кызы белән танышырга телим. Фотосурәтләр белән килгән барлык хатларга да җавап бирәм.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 3000 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк. Хатларыгызны бер ай алдан җибәрүегезне сорыйбыз.

* * *

Арча районы, Иске Ашыт авылында яшәүче әтиебез Мидхәт Фәйзуллинга 12 июльдә 70 яшь тула. Әтиебез! Сине чын күңелебездән юбилееӊ белән котлыйбыз! Сиңа озын гомер, нык сәламәтлек, кайгы-хәсрәтсез, тыныч тормыш телибез.

Иң изге теләкләр белән: улларың, киленнәрең, кызың, киявең, оныкларың.

* * *

Башкортостанның Бүздәк районы, Кәпәй-Кобау авылында яшәүче кадерле әниебез Разия белән әтиебез Фазылҗан Нәбиуллиннарның бергә тормыш итүләренә 15 июльдә 55 ел тула. Әти һәм әни! Сезгә тазалык, кайгы-хәсрәт күрмичә тигез яшәвегезне телибез.

Иң изге теләкләр белән: балаларыгыз, оныкларыгыз.

* * *

Әлмәт шәһәрендә яшәүче кадерле әниебез Мәсгудә Сәхәповага 15 июльдә 57 яшь тула. Әни! Без сине чын күңелдән туган көнең белән тәбрик итәбез, корычтай нык сәламәтлек, куанычлы, якты көннәр, җан тынычлыгы, шатлык-бәхетләр телибез!

Иң изге теләкләр белән: барлык балаларың исеменнән, кызың Фәния, киявең, оныгың.

* * *

Чаллы шәһәрендә яшәүче әниебез Нурания Ганиевага 16 июльдә 55 яшь тула. Кадерле әниебезне чын күңелебездән туган көне белән тәбрик итәбез, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, алдагы тормышында шомырт чәчәгедәй ак бәхетләр юлдаш булуын телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызы, уллары, кияве, килене һәм оныклары.



Баш мөхәррир урынбасары
Миңназыйм СӘФӘРОВ
(53-07-52)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 203620

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6116